**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 2 апрель

№ 209

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендәге, 2 нче пунктының икенче абзацындагы, 3 нче пунктының өченче абзацындагы «бюджет һәм автоном учреждениеләре» сүзләрен «оешмалары» сүзләренә алыштырырга;

карарның 1 нче пунктының икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм социаль яклау дәүләт учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларына һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (механизм теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләренең һәм социаль яклау дәүләт учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларына һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\209.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 1 август, 653 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 2 апрель, 209 нчы
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 ел, 18 август, 592 нче карары нигезендә эшләнде һәм хезмәткәрләрнең окладларын, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләре күләмнәрен һәм шартларын, шулай ук аларны билгеләү критерийларын формалаштыру тәртибен билгели.

1.2. Бу Нигезләмә максатында анда түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

хезмәт өчен түләү системасы – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, база окладлары (база вазыйфаи окладлары, эш хакының база ставкалары), окладлар (вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары) күләмнәрен кертеп, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады (вазыйфаи база оклады), эш хакының база ставкасы – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшче һөнәре буенча яки тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган житәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең минималь оклады (вазыйфаи окладлы), эш хакы ставкасы, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча;

оклад (вазыйфаи оклад) – календарь аенда билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәт өчен түләүнең билгеләп куелган

күләме, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча;

тариф ставкасы – вакыт берәмлегенә билгеле бер катлаулылыктагы (квалификацияле) хезмәт нормасын үтәгән өчен хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән күләме, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча;

эш хакы (хезмәткәр хезмәте өчен түләү) – башкарыла торган эшнең квалификациясенә, катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына бәйле булган хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль шартлардан тайпыла торган эш өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр – стимуллаштыру характерындагы өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү түләүләре;

социаль характердагы түләүләр – социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән, хезмәт өчен түләү фонды акчасын экономияләү хисабына гамәлгә ашырыла торган, ләкин аларның хезмәт функцияләрен үтәүләренә бәйле булмаган түләүләр.

1.3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең (алга таба – хезмәткәрләр) эш хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән билгеләнә:

окладлардан (вазыйфаи окладлардан), эш хакы ставкаларыннан;

компенсация характерындагы түләүләрдән;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән.

## 2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең база окладларын формалаштыру тәртибе

2.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең база оклады күләме Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең беренче разрядлы тариф ставкасы (оклады) белән Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча тариф челтәренең тиешле разрядара коэффициенты тапкырчыгышы буларак билгеләнә.

2.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең беренче разряды тариф ставкасы (оклады) күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан

билгеләнә.

2.3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең база окладлары (вазыйфаи окладлары, эш хакы ставкалары) 1 нче таблицада китерелгән Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәре нигезендә билгеләнә.

1 нче таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәре

| Хезмәт өчен түләү разрядлары | 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| Тариф коэффициентлары | 1,0 | 1,23 | 1,43 | 1,5 |

2.4. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең (2.5 нче пунктта күрсәтелгән вазыйфалардан тыш) база окладлы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_b = T_1 \times K_{mi},$$

монда:

$O_b$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең база оклады (вазыйфаи оклады, эш хакы ставкасы) күләме;

$T_1$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең беренче разряды тариф ставкасы (оклады);

$K_{mi}$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча дүрт разрядлы тариф челтәренең тиешле разрядара коэффициенты.

2.5. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең база оклады беренче квалификация дәрәҗәсендәге «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә икенче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары», «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары»,

«Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган вазыйфалар өчен түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_b = T_1 \times K_{mi} \times K_{mj},$$

монда $K_{mj}$ – тармакның өстенлеге коэффициенты.

Тармакның өстенлеге коэффициенты күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

төп гомуми белеме, урта гомуми белеме һәм квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,000;

урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,166;

бакалавриат югары белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,223;

специалитет яки магистратура югары белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,166.

2.5.1. Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларның, акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йортлары-интернатларның педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_b = T_1 \times K_{mi} \times K_{mj},$$

тармак өстенлеге коэффициенты күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларның, акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йортлары-интернатларның педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр өчен – 1,210;

«Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләре өчен – 1,050;

«Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләре өчен – 1,155;

«Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләре өчен – 1,050.

2.6. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү разряды, тиешле вазыйфаны биләү өчен кирәкле белем дәрәҗәсенә карата таләпләргә таянып, 2 нче таблица нигезендә билгеләнә.

2 нче таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча разрядлар билгеләү өчен нигезләр

| Т/с | Хезмәт өчен түләү разрядлары | Тиешле вазыйфаны биләү өчен кирәкле белем дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| 1. | 1 | Төп гомуми һәм урта гомуми белем |
| 2. | 2 | Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме |
| 3. | 3 | Югары белем – бакалавриат |
| 4. | 4 | Югары белем – специалитет яки магистратура |

2.7. Әгәр били торган вазыйфа югары белем – бакалавриат йә специалитет яки магистратура, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме булуны таләп итмәсә, бакалавриат йә специалитет яки магистратура югары белеме, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме булган затлар били торган вазыйфалар буенча хезмәт өчен түләүнең урта гомуми белемгә туры килә торган разряды билгеләнә.

2.8. Вазыйфага карата квалификация таләпләре белемнең төрле дәрәҗәләрен күздә тоткан очракта, хезмәт өчен түләүнең фактта булган белем дәрәҗәсенә туры килә торган разряды билгеләнә.

2.9. Әгәр вазыйфаны биләүгә эшчәнлекнең төп юнәлешеннән аерыла торган һөнәр белеме булган хезмәткәрләр кертелсә, аларга хезмәт өчен түләүнең фактта булган белем дәрәҗәсенә туры килә торган разряд билгеләнә.

## 3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү разрядларын билгеләү

3.1. Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү разрядлары 3 нче таблицада китерелә.

3 нче таблица

| Т/с | Вазыйфа исеме | Разрядлар диапазоны |
|---|---|---|
| 1. | «Социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы икенче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 1.1.1. | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча техник | 2 |
| 1.1.2. | Социаль хезмәткәр | 1 - 2 |
| 2. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.1.1. | Инвалидларга һөнәри юнәлеше бирү буенча белгеч | 4 |
| 2.1.2. | Хезмәт физиологиясе буенча белгеч | 4 |
| 2.1.3. | Эргономика буенча белгеч | 4 |
| 2.1.4. | Социаль эш буенча белгеч | 3 – 4 |
| 2.1.5. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор-методист | 4 |
| 2.2. | Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.2.1. | Биолог | 4 |
| 2.2.2. | Зоолог | 4 |
| 2.2.3. | Энтомолог | 4 |
| 2.2.4. | Медицина психологы | 4 |
| 2.2.5. | Инвалидларны тернәкләндерү буенча белгеч | 4 |
| 2.2.6. | Ионлаштыручы һәм ионлаштырмаучы нурланыш чыганакларын тикшерү буенча эксперт-физик | 4 |
| 2.2.7. | Сәламәтлек саклау учреждениеләре химик-эксперты | 4 |
| 2.2.8. | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча инженер | 4 |
| 2.3. | Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.3.1. | Инвалидларны һөнәри тернәкләндерү буенча консультант | 4 |
| 2.4. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.4.1. | Бүлек (социаль хезмәт) мөдире | 3 – 4 |

3.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү разрядлары 4 нче таблицада китерелә.

4 нче таблица

| Т/с | Вазыйфа исеме | Разрядлар диапазоны |
|---|---|---|
| 1. | Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1.1. | Тәрбияче ярдәмчесе | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.1.1. | Кече тәрбияче | 1 – 2 |
| 3. | Педагог хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| 3.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 3.1.1. | Хезмәт буенча инструктор | 2 – 4 |
| 3.1.2. | Физик культура буенча инструктор | 2 – 4 |
| 3.1.3. | Музыка җитәкчесе | 2 – 4 |
| 3.2. | Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 3.2.1. | Инструктор-методист | 3 – 4 |
| 3.2.2. | Концертмейстер | 2 – 4 |
| 3.2.3. | Социаль педагог | 2 – 4 |
| 3.3. | Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 3.3.1. | Тәрбияче | 2 – 4 |
| 3.3.2. | Методист | 3 – 4 |
| 3.3.3. | Педагог-психолог | 2 – 4 |
| 3.3.4. | Өлкән инструктор-методист | 3 – 4 |
| 3.4. | Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 3.4.1. | Өлкән тәрбияче | 3 – 4 |
| 3.4.2. | Өлкән методист | 3 – 4 |
| 3.4.3. | Укытучы | 2 – 4 |
| 3.4.4. | Укытучы-дефектолог | 3 – 4 |
| 3.4.5. | Укытучы-логопед (логопед) | 3 – 4 |

3.3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү разрядлары 5 нче таблицада китерелә.

5 нче таблица

| Т/с | Вазыйфа исеме | Разряд |
|---|---|---|
| 1. | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм фәнни хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 1.1.1. | Кече фәнни хезмәткәр | 4 |
| 1.1.2. | Фәнни хезмәткәр | 4 |
| 1.2. | Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 1.2.1. | Өлкән фәнни хезмәткәр | 4 |
| 1.3. | Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 1.3.1. | Әйдәп баручы фәнни хезмәткәр | 4 |

| | | |
|---|---|---|
| 1.4. | Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 1.4.1. | Баш фәнни хезмәткәр | 4 |

3.4. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү разрядлары 6 нчы таблицада китерелә.

6 нчы таблица

| Т/с | Вазыйфа исеме | Разряд |
|---|---|---|
| 1. | «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 1.1.1. | Санитар хатын-кыз | 1 |
| 1.1.2. | Санитар хатын-кыз (юучы) | 1 |
| 1.1.3. | Авырулар караучы кече шәфкать туташы | 1 |
| 1.1.4. | Хуҗа-туташ | 1 |
| 2. | «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.1.1. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 2 |
| 2.1.2. | Хезмәт терапиясе буенча инструктор | 2 |
| 2.1.3. | Стерилизацияләү бүлеге шәфкать туташы | 2 |
| 2.1.4. | Медицина дезинфекторы | 1 – 2 |
| 2.1.5. | Медицина теркәүчесе | 1 – 2 |
| 2.2. | Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.2.1. | Балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы буенча табиб (туклану гигиенасы буенча табиб, хезмәт гигиенасы буенча табиб, гигиена тәрбиясе бирү буенча табиб, коммуналь гигиена буенча табиб, гомуми гигиена буенча табиб, табиб-паразитолог, радиация гигиенасы буенча табиб, табиб-эпидемиолог) ярдәмчесе | 2 |
| 2.2.2. | Диета буенча шәфкать туташы | 2 |
| 2.3. | Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.3.1. | Шәфкать туташы | 2 |
| 2.3.2. | Палата (пост) шәфкать туташы | 2 |
| 2.3.3. | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | 2 |
| 2.3.4. | Массаж буенча шәфкать туташы | 2 |
| 2.4. | Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.4.1. | Фельдшер | 2 |
| 2.4.2. | Процедуралар шәфкать туташы | 2 |
| 2.4.3. | Бәйләү буенча шәфкать туташы | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. | Бишенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.5.1. | Өлкән шәфкать туташы (акушер, фельдшер, операция бүлеге, теш техникы шәфкать туташы) | 2 |
| 3. | «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | |
| 3.2. | Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 3.2.1. | Табиб-белгечләр (3 нче һәм 4 нче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 4 |
| 3.3. | Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 3.3.1. | Дәвалау-профилактика учреждениеләренең, ашыгыч медицина ярдәме станцияләренең (бүлекләренең) стационар бүлекчәләре табиб-белгечләре | 4 |
| 3.3.2. | Участок табиб-терапевтлары | 4 |
| 3.3.3. | Гомуми практика табиблары (гаилә табиблары) (дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 4 |
| 3.4. | Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 3.4.1. | Өлкән табиб | 4 |
| 3. | «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| 4.1. | Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 4.1.1. | Структур бүлекчә (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдире (стационарларның хирургия юнәлешендәге бүлекләре мөдирләреннән тыш) | 4 |

3.5. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү разрядлары 7 нче таблицада китерелә.

7 нче таблица

| Т/с | Вазыйфа исеме | Разрядлар диапазоны |
|---|---|---|
| 1. | «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Мәдәни чаралар оештыручы | 2 – 4 |
| 1.2. | Аккомпаниатор | 2 – 4 |
| 2. | «Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Китапханәче | 2 – 4 |
| 2.2. | Мөхәррир | 2 – 4 |

## 4. Хезмәткәрләр эш хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгатьләр нормасы

4.1. Педагог хезмәткәрләр өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 333 статьясы нигезендә атнага иң күбе 36 сәгатьлек кыскартылган эш вакыты дәвамлылыгы билгеләнә.

Эш хакы ставкасы өчен педагогик (укыту) эш сәгатьләре нормасы йә эш вакыты озынлыгы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагог хезмәткәрләрнең эш вакыты озынлыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) турында» 2010 ел, 24 декабрь, 2075 нче приказы белән билгеләнгән Медицина хезмәткәрләре өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 350 статьясы нигезендә кыскартылган эш вакыты (атнага иң күбе 39 сәгать) билгеләнә. Вазыйфага һәм (яки) белгечлеккә бәйле рәвештә медицина хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Медицина хезмәткәрләренең алар били торган вазыйфага һәм (яки) белгечлеккә бәйле булган эш вакыты озынлыгы турында» 2003 ел, 14 февраль, 101 нче карары белән билгеләнә.

4.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең башка хезмәткәрләренең, шул исәптән җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм структур бүлекчәләре җитәкчеләренең вазыйфаи окладлары, хезмәт турындагы законнар нигезендә эш вакытының башка озынлыгы билгеләнмәсә, 40 сәгатьлек эш атнасындагы эш өчен түләнә.

## 5. База оклады (эш хакы ставкасы) өчен халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең норматив саны

5.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрдә эш хакының база ставкасы (база оклады) өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар санының тәкъдим ителә торган нормативы түбәндәгеләрне тәшкил итә:

социаль хезмәткәрләр тарафыннан:

10 кеше – шәһәр җирендә,

6 кеше – авыл җирендә;

медицина хезмәткәрләре тарафыннан:

12 кеше – шәһәр һәм авыл җирендә.

## 6. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

6.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады

түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N},$$

монда:

$O_d$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$H_f$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_N$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең эш хакы база ставкасы (база оклады) өчен сәгатьләр нормасы.

## 7. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

7.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләрен хезмәтнең сыйфатлы нәтиҗәсенә ирешүгә стимуллаштыруга юнәлдерелгән түләүләр, шулай ук башкарган эш өчен бүләкләү керә.

7.1.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

интенсивлылык һәм эшнең югары нәтиҗәләре өчен түләүләрне;

вазыйфа буенча эш стажы өчен түләүләрне;

квалификация категориясе өчен түләүләрне;

башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрне;

премиаль һәм башка бүләкләү түләүләрен.

7.1.2. Интенсивлылык һәм эшнең югары нәтиҗәләре өчен түләүләр түбәндәгеләргә бүленә:

эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;

идарә иткән өчен түләүләр;

мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр;

гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр;

эшнең катлаулылыгы өчен түләүләр.

7.2. Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

7.2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр квалификация тасвирнамәләре нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре яктылыгында аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тота торган белгечлекләр буенча

эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ – квалификация категориясе өчен түләү;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә өстәмә түләүләр күләмнәре 8 нче таблицада китерелә.

8 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Т/с | Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | 1 | 2 нче квалификация категориясе | 5 |
| | | 1 нче квалификация категориясе | 10 |
| | | югары квалификация категориясе | 15 |
| 1.2. | 2 | 2 нче квалификация категориясе | 7 |
| | | 1 нче квалификация категориясе | 12 |
| | | югары квалификация категориясе | 20 |
| 1.3. | 3 | 2 нче квалификация категориясе | 7 |
| | | 1 нче квалификация категориясе | 12 |
| | | югары квалификация категориясе | 20 |
| 2. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | 1 | 2 нче квалификация категориясе | 12 |
| | | 1 нче квалификация категориясе | 17 |
| | | югары квалификация категориясе | 22 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр билгеләү (үзгәртү) каршында аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы нигезендә аттестация комиссиясе карар чыгарган көннән гамәлгә ашырыла.

7.2.2. Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның билгеләнгән категорияләре белән эшләгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Бүлекчәдәге һәм вазыйфадагы эшнең тәгаен шартларын исәпкә алып, аларга эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге, сайланулы һөнәр берлеге органы (яки хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе тарафыннан раслана.

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

7.2.3. Структур бүлекчә белән идарә иткән өчен түләүләр «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{ysp} = O_d \times D_{ysp},$$

монда:

$B_{ysp}$ – структур бүлекчә белән идарә иткән өчен түләүләр;

$D_{ysp}$ – структур бүлекчә белән идарә иткән өчен өстәмә түләү күләме.

Структур бүлекчә белән идарә иткән өчен өстәмә түләү күләме 35 процент тәшкил итә.

7.2.4. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыру өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә тиешле түләүләрне бирү өчен нигез булып торучы мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре исемлеге бу Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.

Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән гамәлгә ашырыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме, ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү хезмәткәрнең үз теләге буенча түләү мактаулы исемнең берсе, дәүләт бүләгенең берсе буенча билгеләнә.

7.2.5. Эшнең катлаулылыгы өчен түләүләр сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен түләүләр;

$D_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 9 нчы таблицада китерелә.

9 нчы таблица

Эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | «Социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә икенче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 12 |
| 2. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 10 |
| 3. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 20 |

7.2.6. Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр, юнәлеш буенча эшнең дәвамлылыгына карап, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү;

$D_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 10 нчы таблицада китерелә.

10 нчы таблица

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж төркеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| 1. | «Социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы икенче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 2 елдан 3 елга кадәр | 1,5 |
| | | | 3 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | | 10 елдан артык | 5 |
| 2. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр | 1 – 3 | 2 елдан 3 елга кадәр | 2,5 |
| | | | 3 елдан 5 елга кадәр | 3,5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | 5 елдан 10 елга кадәр | 5 |
| | | | 10 елдан 15 елга кадәр | 7 |
| | | | 15 елдан артык | 10 |
| 3. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 2 елдан 3 елга кадәр | 2,5 |
| | | | 3 елдан 5 елга кадәр | 3,5 |
| | | | 5 елдан 10 елга кадәр | 5 |
| | | | 10 елдан 15 елга кадәр | 7 |
| | | | 15 елдан артык | 10 |

Эш стажы үзгәргәндә юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стаж тулган көннән, стажны раслый торган кирәкле документ кертелгән көннән гамәлгә ашырыла.

Юнәлеш буенча эш стажына эш чорлары 11 нче таблица нигезендә исәпләнә.

11 нче таблица

Аларны билгән чор сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләргә юнәлеш буенча эш стажына керә торган вазыйфалар исемлеге

| Т/с | Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфалары исеме | Аларда эшләү чорлары юнәлеш буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар |
|---|---|---|
| 1. | Социаль хезмәткәр; социаль эш буенча белгеч; бүлек (социаль хезмәт) мөдире | Социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы икенче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары |

7.2.7. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре хезмәткәрләргә юбилей даталарына, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алуга туры китереп һәм башка нигезләр буенча билгеләнгән чор (ай, квартал, ел)

өчен бер тапкыр билгеләнә.

Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре күләмнәре, аларны гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

7.2.8. Хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү фонды буенча экономия Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән күздә тотылган тәртиптә премияләр һәм бүләкләү түләүләре рәвешендәге стимуллаштыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

7.3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

7.3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр педагог хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә квалификация категориясенең гамәли вакыты чикләрендә аларның гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ – квалификация категориясе өчен түләү;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 12 нче таблицада китерелә.

12 нче таблица

Квалификация категориясе өчен педагог хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә бирелә торган өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Педагог хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | 1 | 2 квалификация категориясе | 4,5 |
| | | 1 квалификация категориясе | 6,0 |
| | | югары квалификация категориясе | 7,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.2. | 2 | 2 квалификация категориясе | 4,5 |
| | | 1 квалификация категориясе | 7,5 |
| | | югары квалификация категориясе | 10,0 |
| 1.3. | 3 | 2 квалификация категориясе | 6,0 |
| | | 1 квалификация категориясе | 8,5 |
| | | югары квалификация категориясе | 12,5 |
| 1.4. | 4 | 2 квалификация категориясе | 7,5 |
| | | 1 квалификация категориясе | 10,0 |
| | | югары квалификация категориясе | 15,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр билгеләү (үзгәртү) каршында аттестация комиссиясе төзелгән орган приказы нигезендә аттестация комиссиясе карар чыгарган көннән гамәлгә ашырыла.

7.3.2. Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның билгеләнгән категорияләре белән эшләгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүнең тәкъдим ителә торган күләме.

Бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең тәгаен шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемлеге, сайланулы һөнәр берлеге органы (яки хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе тарафыннан раслана.

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

7.3.3. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Алар булган өчен мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре исемлеге бу Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада китерелә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның тармак бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау кәгазе булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау кәгазе булган өчен өстәмә түләү Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры) приказы белән бүләкләнә торган мәгариф хезмәткәрләренә билгеләнә.

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры приказы нигезендә билгеләнә.

Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән гамәлгә ашырыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме, ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү хезмәткәр теләге буенча мактаулы исемнәрнең берсе, дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

7.3.4. Эшнең катлаулылыгы өчен түләүләр балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларның, акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йортлары-интернатларның педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен түләүләр;

$D_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 13 нче таблицада китерелә.

13 нче таблица

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Педагог хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 1 – 4 | 50 |

7.3.5. Юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә юнәлеш буенча эшнең дәвамлылыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен түләү;

$D_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 14 нче таблицада китерелә.

14 нче таблица

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж төркеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 4 яшьтән 10 яшькә кадәр | 2,0 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 3,0 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 4,0 |
| 2. | Педагог хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 2 яшьтән 6 яшькә кадәр | 3,0 |
| | | 6 яшьтән 10 яшькә кадәр | 4,5 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 5,5 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 6,5 |

Эш стажы үзгәргәндә юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стаж тулган көннән, стажны раслый торган кирәкле документ кертелгән көннән гамәлгә ашырыла.

Педагогик эш стажына 15 нче таблица нигезендә оешмаларда башкарган педагогик, җитәкчелек итү һәм методик эш кертелә.

15 нче таблица

Аларда эшләгән вакыт мәгариф хезмәткәрләренең педагогик эш стажына исәпләнә торган оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге

| Т/с | Оешмалар исеме | Вазыйфалар исеме |
|---|---|---|
| 1. | Белем бирү оешмалары (шул исәптән югары белем бирүче мәгариф оешмалары, хәрби һөнәр оешмалары һәм югары белем бирүче хәрби белем бирү оешмалары, белгечләргә өстәмә һөнәр белеме бирү (квалификация күтәрү) оешмалары; медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары | укытучылар, мөгаллимнәр, укытучы-дефектологлар, укытучы-логопедлар (логопедлар), укытучы-оештыручылар (тереклек эшчәнлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакыру алды әзерлеген), физик тәрбия бирү буенча җитәкчеләр, өлкән мастерлар, производствога өйрәтү (шул исәптән транспорт чараларын йөртүгә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә, язу машинкаларында һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү) буенча мастерлар, өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирүче педагоглар, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар, физкультура буенча инструкторлар, хезмәт буенча инструкторлар, директорлар (башлыклар, мөдирләр), директорларның (башлыкларның, мөдир- |

| | | |
|---|---|---|
| | | ләрнең) уку-укыту, уку-укыту-тәрбия, уку-укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эше, производствога өйрәтү (эше), чит тел, уку-укыту-очуга әзерләү, гомуми белем буенча әзерлек, режим буенча урынбасарлары, уку-укыту часте мөдирләре, практика, уку-укыту-консультация пунктлары, логопедия пунктлары, интернатлар, бүлекләр, бүлекчәләр, лабораторияләр, кабинетлар, секцияләр, филиаллар, курслар һәм эшчәнлекләре белем (тәрбия) бирү процессына, методик тәэмин итүгә бәйле булган башка структур бүлекчәләр мөдирләре (башлыклары);<br>режим буенча өлкән кизүләр, режим буенча кизүләр, аккомпаниаторлар, мәдәни чаралар оештыручылар, экскурсоводлар;<br>профессор-укытучылар составы |
| 2. | Барлык исемдәге методик (уку-укыту-методик) оешмалар (кайсы ведомствога буйсынуларына карамастан) | секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр җитәкчеләре, аларның урынбасарлары; мөдирләре, эшчәнлекләре методик тәэмин итүгә бәйле булган фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| 3. | Мәгариф белән идарә итү органнары һәм белем бирү оешмаларына җитәкчелек итүне гамәлгә ашыручы органнар (структур бүлекчәләр. Техник белем бирү бүлекләре (бюросы), министрлыкларның (ведомстволарның) җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларының, бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре | җитәкчелек итүче, инспектор, методист вазыйфалары, белгечләрнең инструктор вазыйфалары, шулай ук башка вазыйфалары (икътисадый, финанс, хуҗалык эшчәнлегенә, төзелешкә, тәэмин итүгә, эш башкаруга бәйле булган вазыйфаларда эшләүдән тыш);<br>штаттагы укытучылар, эшчеләрне производствога өйрәтү буенча мастерлар, эшчәнлекләре кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән |

| | | |
|---|---|---|
| | | бәйле булган җитәкчелек итүче, инспектор, инженер, методист вазыйфалары |
| 4. | РОСТО (ДОСААФ) һәм гражданнар авиациясенең белем бирү оешмалары | җитәкчелек итүче, команда-очучы, команда-инструкторлар, инженер-инструкторлар, инструкторлар һәм укытучылар составлары, производ-ствога өйрәтү буенча мастерлар, инженер-инструктор-методистлар, инженер-очучы-методистлар |
| 5. | Оешмаларның, предприятиеләрнең тулай тораклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачылар театрлары, курчак театрлары, предприятиеләрнең һәм оешмаларның балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча мәдәни-агарту оешмалары һәм бүлекчәләре | тәрбиячеләр, педагог-оештыру-чылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирүче педагоглар (түгәрәкләр җитәкчеләре), инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлар мөдирләре |
| 6. | Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү алып баручы изоляторлар һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары | педагогик белем булганда түбәндәге вазыйфаларда эшләү (хезмәт итү): башлыкның тәрбия эше буенча урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү эше (өйрәтү) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, өлкән инженер һәм җитештерү-техникага өйрәтү буенча инженер, өлкән мастер һәм производствога өйрәтү буенча мастер, өлкән инспектор һәм сак һәм режим буенча инспектор, уку-укыту-техника кабинеты мөдире, психолог |

Башка учреждениеләрдә һәм оешмаларда эшләү, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмларында уку вакыты түбәндәге тәртиптә исәпләнә:

педагог хезмәткәрләргә педагогик эш стажына бернинди шартсыз һәм чикләүсез исәпләнә:

контракт буенча хәрби хезмәттә булган вакыт хәрби хезмәттә булган бер көн - бер эш көне булып, ә хәрби хезмәттә чакыру буенча булган вакыт хәрби хезмәттәге бер көн ике эш көне булып санала;

фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләгән вакыт;

педагог хезмәткәрләргә педагогик эш стажына түбәндәге шарт үтәлгәндә түбәндәге чорлар исәпләнә, әгәр дә аерым алганда да, бергә алганда да алар алдыннан һәм алардан соң турыдан-туры педагогик эшчәнлек гамәлгә ашырылса:

СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, старшина составлары, прапорщиклар һәм мичманнар вазыйфаларында (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, дәүләт иминлеге органнарында) хезмәт иткән вакыт, хәрби хезмәттә контракт буенча һәм чакыру буенча булган вакыттан тыш;

Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән (мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) хезмәткәрләре һөнәр берлегенең территориаль оешмалары аппаратларында (комитетларында, советларында) житәкчелек итүче, инспектор, инструктор вазыйфаларында һәм белгечләрнең башка вазыйфаларында; һөнәр берлеге органнарында сайланулы вазыйфаларда; педагогик җәмгыятьләрдә һәм Балалар фонды идарәләрендә инструктор һәм методист вазыйфаларында; Укытучылар (халык мәгарифе, һөнәри техник белем бирү хезмәткәре) йорты директоры (мөдире) вазыйфасында; балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә яки  эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләрендә, балигъ булмаганнарның хокук бозуларын кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекцияләрдә, милициянең балалар бүлмәләрендә) эшләү вакыты;

аспирантурада, һөнәр белеме бирүче мәгариф оешмаларында һәм дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф оешмаларында уку (көндезге формада) вакыты.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләгән вакыт, әгәр дә бу вазыйфаларда эшләгән чорда хезмәткәрнең педагогик белеме булса яки ул һөнәр белеме бирү оешмасында яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында белем алган булса, педагогик эш стажына исәпләнә.

Белем бирү оешмаларында төп эштән тыш сәгатькә карап түләнә торган шартларда башкарыла торган педагогик эш вакыты педагогик стажга аның күләме (бер яки берничә белем бирү оешмасында) уку елында кимендә 180 сәгать тәшкил иткән шартларда кертелә. Бу вакытта педагогик стажга бары тик педагогик эш башкарылган айлар гына исәпләнә.

Оешмалардагы эшнең һәм СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итүнең эш юнәлешенә, укытыла торган предметка (курска, дисциплинага, түгәрәккә) туры килү-килмәве турындагы тәгаен мәсьәләләрне хәл итү хокукы, хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы белән килештереп, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесенә бирелә.

7.3.6. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре хезмәткәрләргә юбилей даталарына, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен

алуга туры китереп һәм башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре күләмнәре, аларны гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

7.3.7. Хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү фонды буенча экономия Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән күздә тотылган тәртиптә премияләр һәм бүләкләү түләүләре рәвешендәге стимуллаштыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

7.4. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

7.4.1. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Алар булган өчен фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре исемлеге бу Нигезләмәгә теркәлгән 4 нче кушымтада китерелә.

Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән гамәлгә ашырыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме, ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү хезмәткәр теләге буенча мактаулы исемнәрнең берсе, дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

7.4.2. Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр структур

бүлекчәләр хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{ysz} = O_d \times D_{ysz},$$

монда:

$B_{ysz}$ – гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләү;

$D_{ysz}$ – гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәрнең бердәм реестрына кертелгән гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр өчен бирелә.

Гыйльми дәрәҗә булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү гыйльми дәрәҗә бирү турында карар үз көченә кергән көннән башкарыла. Фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен бирү турында карар аны Югары аттестация комиссиясе президиумы кабул иткән көннән үз көченә керә. Фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен бирү турында карар Югары аттестация комиссиясе президиумы фәннәр кандидаты дипломын бирү турында карар кабул иткән көннән үз көченә керә.

Гыйльми исемнәр булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү гыйльми исем бирелгән көннән башкарыла.

Гыйльми дәрәҗәсе һәм гыйльми исеме булган хезмәткәрләргә гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр күләме гыйльми дәрәҗә һәм гыйльми исем өчен түләүләр суммасы буларак хисаплап чыгарыла.

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 16 нчы таблицада китерелә.

16 нчы таблица

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләү билгеләү нигезе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Структур бүлекчәләрнең фәнни хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе | 60 |
| | | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр | 30 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кандидаты гыйльми дәрәҗәсе | |
| | | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә белгечлек буенча профессор гыйльми исеме | 80 |
| | | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә белгечлек буенча доцент гыйльми исеме | 40 |

7.4.3. Эшнең катлаулылыгы өчен түләүләр фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен түләү;

$D_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләү күләме вазыйфаи окладның 100 процентын тәшкил итә.

7.4.4. Юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендә эшләүнең дәвамлылыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен түләү;

$D_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 17 нче таблицада китерелә.

17 нче таблица

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Структур бүлекчәләрнең фәнни хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | 3 яшьтән 6 яшькә кадәр | 3 |
| | | 6 яшьтән 10 яшькә кадәр | 5 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 8 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 10 |

Эш стажы үзгәргәндә юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стаж тулган көннән, стажны раслый торган кирәкле документ кертелгән көннән гамәлгә ашырыла.

Юнәлеш буенча эш стажына 18 нче таблица нигезендә эш чорлары исәпләнә.

18 нче таблица

Аларда эшләү чоры фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренә юнәлеш буенча эш стажына исәпләнә торган вазыйфалар исемлеге

| Т/с | Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфалары исеме | Аларда эшләү чорлары юнәлеш буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар |
|---|---|---|
| 1. | Кече фәнни хезмәткәр, фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, баш фәнни хезмәткәр | структур бүлекчәләрнең фәнни хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеменең 1 – 5 нче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән структур бүлекчәләрнең фәнни хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре вазыйфалары |

7.4.5. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре хезмәткәрләргә юбилей даталарына, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алуга туры китереп һәм башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре күләмнәре, аларны гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә

7.4.6. Хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү фонды буенча экономия Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм

дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән күздә тотылган тәртиптә премияләр һәм бүләкләү түләүләре рәвешендәге стимуллаштыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

7.5. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

7.5.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация тасвирнамәләре нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре яктылыгында аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тота торган белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ – квалификация категориясе өчен түләү;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 19 нчы таблицада китерелә.

19 нчы таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| 1. | «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | 2 квалификация категориясе | 3 |
| 1.2. | 1 квалификация категориясе | 6 |
| 1.3. | югары квалификация категориясе | 10 |
| 2. | «Табиблар һәм провизорлар» вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.2. | 2 квалификация категориясе | 6 |
| 2.3. | 1 квалификация категориясе | 10 |
| 2.4. | югары квалификация категориясе | 20 |
| 3. | «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| 3.1. | 2 квалификация категориясе | 6 |
| 3.2. | 1 квалификация категориясе | 10 |
| 3.3. | югары квалификация категориясе | 20 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр билгеләү (үзгәртү) аттестация комиссиясе карары чыгарылган көннән каршында аттестация комиссиясе төзелгән орган приказы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Квалификация категориясе медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре үзләренә квалификация категориясе бирелгән белгечлек буенча эшләгәндә исәпкә алына.

Табиблар - структур бүлекчәләр житәкчеләренә квалификация категориясе үзләренә квалификация категориясе бирелгән белгечлек җитәкчелек итела торган бүлекчә юнәлешенә туры килгән очракта исәпкә алына.

7.5.2. Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның билгеләнгән категорияләре белән эшләгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләү;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең тәгаен шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемлеге, сайланулы һөнәр берлеге органы (яки хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе тарафыннан раслана.

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

7.5.3. Идарә иткән өчен түләүләр «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы», «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы», «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) житәкчеләре» һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган, идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{ysp} = O_d \times D_{ysp},$$

монда:

$B_{ysp}$ – идарә иткән өчен түләү;

$D_{ysp}$ – идарә иткән өчен өстәмә түләү күләме.

Идарә иткән өчен өстәмә түләү күләме 20 нче таблицада китерелә.

20 нче таблица

Идарә иткән өчен түләү күләме

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | хужа-туташ | 10 |
| 2. | «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | 5 | 20 |
| 3. | «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 20 |

7.5.4. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә

Алар булган өчен медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре исемлеге бу Нигезләмәгә теркәлгән 5 нче кушымтада китерелә.

Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән гамәлгә ашырыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме, ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган

хезмәткәрләргә мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өчен түләү хезмәткәр теләге буенча мактаулы исемнәрнең берсе, дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

7.5.5. Гыйльми дәрәҗә булган өчен түләүләр «Табиблар һәм провизорлар» һәм «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{ysp} = O_d \times D_{ysp},$$

монда:

$B_{ysz}$ – гыйльми дәрәҗә булган өчен түләү;

$D_{ysz}$ – гыйльми дәрәҗә булган өчен өстәмә түләү күләме.

Гыйльми дәрәҗә булган өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәрнең бердәм реестрына кертелгән гыйльми дәрәҗәләр өчен бирелә.

Гыйльми дәрәҗә булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү гыйльми дәрәҗә бирү турында карар үз көченә кергән көннән башкарыла. Фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен бирү турында карар аны Югары аттестация комиссиясе президиумы кабул иткән көннән үз көченә керә. Фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен бирү турында карар Югары аттестация комиссиясе президиумы фәннәр кандидаты дипломын бирү турында карар кабул иткән көннән үз көченә керә.

Гыйльми дәрәҗә булган өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 21 нче таблицада китерелә.

21 нче таблица

Гыйльми дәрәҗә булган өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Гыйльми дәрәҗәләр булган өчен өстәмә түләү билгеләү нигезе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе | 30 |
| | | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе | 15 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркеме | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе | 30 |
| | | фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе | 15 |

7.5.6. Эшнең катлаулылыгы өчен түләүләр «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы», «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен түләү;

$D_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 22 нче таблицада китерелә.

22 нче таблица

Эшнең катлаулылыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 20 |
| 2. | «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | 1 | 20 |
| | | 2 | 25 |
| | | 3 | 30 |
| | | 4 | 35 |
| | | 5 | 40 |
| 3. | «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | 2 | 40 |
| | | 3 | 45 |
| | | 4 | 50 |
| 4. | «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле | 1 | 10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркеме | | |

7.5.7. Юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә юнәлеш буенча эшләүнең дәвамлылыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен түләү;

$D_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 23 нче таблицада китерелә.

23 нче таблица

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т\с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж төркеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | 2 яшьтән 5 яшькә кадәр | 2,5 |
| | | 5 яшьтән 10 яшькә кадәр | 4,0 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 4,5 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 5,5 |
| 2. | «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | 3 яшьтән 5 яшькә кадәр | 2,5 |
| | | 5 яшьтән 10 яшькә кадәр | 3,5 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 4,5 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 5,5 |
| 3. | «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | 3 яшьтән 5 яшькә кадәр | 5,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 5 яшьтән 10 яшькә кадәр | 7,5 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 9,0 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 10,0 |
| 4. | «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркеме | 3 яшьтән 5 яшькә кадәр | 5,0 |
| | | 5 яшьтән 10 яшькә кадәр | 7,5 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 9,0 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 10,0 |

Эш стажы үзгәргәндә юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стаж тулган көннән, стажны раслый торган кирәкле документ кертелгән көннән гамәлгә ашырыла.

Юнәлеш буенча эш стажына 24 нче таблица нигезендә барлык милек рәвешендәге учреждениеләрдә һәм оешмаларда медицина, җитәкчелек итү һәм методик эш исәпләнә.

24 нче таблица

Аларда эшләгән вакыт медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә юнәлеш буенча эш стажына исәпләнә торган вазыйфалар исемлеге

| Т/с | Юнәлеш буенча вазыйфалар исеме |
|---|---|
| 1. | Табиб, провизор, җитәкче (табиб, провизор) («Табиблар һәм провизорлар», «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркемнәренә кертелгән вазыйфалар) |
| 2. | Урта медицина хезмәткәре, фармацевт («Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеменә кертелгән вазыйфалар) |
| 3. | Кече медицина хезмәткәре, фасовкалаучы (Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеменә кертелгән вазыйфалар) |

7.5.8. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре хезмәткәрләргә юбилей даталарына, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алуга туры китереп һәм башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре күләмнәре, аларны гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт

күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

7.5.9. Хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү фонды буенча экономия Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән күздә тотылган тәртиптә премияләр һәм бүләкләү түләүләре рәвешендәге стимуллаштыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

7.6. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

7.6.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр һөнәри квалификация төркемнәре яктылыгында аттестация йомгаклары буенча тариф-квалификация тасвирнамәләре нигезендә квалификация категорияләре бирүне күздә тота торган белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ – квалификация категориясе өчен түләү;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 25 нче таблицада китерелә.

25 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т\с | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| 1. | «Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | 2 квалификация категориясе | 5,0 |
| 1.2. | 1 квалификация категориясе | 7,5 |
| 1.3. | югары квалификация категориясе | 12,5 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр билгеләү (үзгәртү) каршында аттестация комиссиясе төзелгән орган приказы нигезендә аттестация комиссиясе карары чыгарылган көннән гамәлгә ашырыла.

7.6.2. Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр «Урта звено мәдәният, сәнгать

һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары», «Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һәм «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчелек итүче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче аерым дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның билгеләнгән категорияләре белән эшләгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләү;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең тәгаен шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемлеге, сайланулы һөнәр берлеге органы (яки хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе тарафыннан раслана.

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

7.6.3. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Алар булган өчен мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре исемлеге бу

Нигезләмәгә теркәлгән 6 нчы кушымтада китерелә.

Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән гамәлгә ашырыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме, ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өчен түләү хезмәткәр теләге буенча мактаулы исемнәрнең берсе, дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

7.6.4. Юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә юнәлеш буенча эшләүнең дәвамлылыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен түләү;

$D_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре 26 нчы таблицада китерелә.

26 нчы таблица

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж төркеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 3 яшьтән 6 яшькә кадәр | 1,5 |
| | | 6 яшьтән 10 яшькә кадәр | 2,0 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 2,5 |
| | | 15 яшьтән артыграк | 3,5 |
| 2. | «Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 3 яшьтән 6 яшькә кадәр | 1,5 |
| | | 6 яшьтән 10 яшькә кадәр | 3,5 |
| | | 10 яшьтән 15 яшькә кадәр | 5,0 |
| | | 15 яшьтән | 6,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | артыграк | |

Эш стажы үзгәргәндә юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стаж тулган көннән, стажны раслый торган кирәкле документ кертелгән көннән гамәлгә ашырыла.

Юнәлеш буенча эш стажына 27 нче таблица нигезендә эш чорлары кертелә.

27 нче таблица

Мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләренә юнәлеш буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар исемлеге

| Т/с | Мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләре вазыйфалары исеме | Аларда эшләгән чорлар юнәлеш буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар |
|---|---|---|
| 1. | Мәдәни чаралар оештыручы | түгәрәк, үзешчән берләшмә, кызыксыну клубы җитәкчесе; бию кичәсен алып баручы, дискотеканы алып баручы, дискотеканың музыка өлеше җитәкчесе, аккомпаниатор; мәдәни чаралар оештыручы |
| 2. | Китапханәче | баш китапханәче; баш библиограф; китапханәче; библиограф; китапханә методисты, китапханә бүлеге (секторы) мөдире |

7.6.5. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре хезмәткәрләргә юбилей даталарына, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алуга туры китереп һәм башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

7.6.6. Хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү фонды буенча экономия Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән күздә тотылган тәртиптә премияләр һәм бүләкләү түләүләре рәвешендәге стимуллаштыру түләүләренә җибәрелергә мөмкин.

7.7. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

7.7.1. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча фактта эшләгән вакыт өчен хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп

критерий булып Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик мәгънәләренә ирешү тора.

7.7.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары, сайланулы һөнәр берлеге органы (яки хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, аның җитәкчесе тарафыннан раслана. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының тәгаен мәгънәләре һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе алдында тора торган бурычлардан чыгып ел саен билгеләнә.

7.7.3. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләмнәре, аларны гамәлгә ашыру шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең локаль норматив актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

7.7.4. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}(I_{ij} \times K_i)} \times \sum_{i=1}^{n}(I_{ij} \times K_i),$$

монда:

$B_{kj}$ – j-хезмәткәргә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр;

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фонды;

$I_{ij}$ – j-хезмәткәр буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-критерие;

$K_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү буенча i-критериеның авырлык коэффициенты;

n – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре саны.

7.7.5. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле үлчәнештәге нәтиҗәлелек критерийларының чагыштырырлык булуын тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериеның мәгънәләре диапазонын (иң яхшысын һәм иң начарын) сайлап алудан гыйбарәт, аларның берсе - нормалаштырылган критерийның нульгә тигез булган мәгънәсенә, икенчесе бергә тигез булган мәгънәсенә туры килә. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериеның мәгънәләре диапазоны чикләрендә нәтиҗәлелек критериеның факттагы мәгънәсен

тапканда эшчәнлекнең нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие 0 дән 1 гә кадәр мәгънәләр ала. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы мәгънәсе иң начардан түбәнрәк мәгънәгә ия булса, нормалаштырылган критерийның мәгънәсе - 0 гә тигез дип, иң яхшыдан югарырак булганда 1 гә тигез дип кабул ителә.

7.7.6. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие мәгънәсе эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерие мәгънәсенә турыдан-туры (уңай динамика критерийның мәгънәсе арту белән билгеләнә) һәм кире (уңай динамика критерийның мәгънәсе кимү белән билгеләнә) бәйле булырга мөмкин.

7.7.7. Нормалаштырылган критерий, аның мәгънәсе критерий мәгънәсенә турыдан-туры бәйле булса, түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда:

$FI_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериеның факттагы мәгънәсе;

$M_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы мәгънәсе;

$L_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериеның иң начар мәгънәсе.

7.7.8. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие аның мәгънәсенә кире бәйлелектә булса, критерий мәгънәсеннән түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - M_i}{L_i - M_i}.$$

7.7.9. Авырлык коэффициентлары белән эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериеның өстенлек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Авырлык коэффициенты түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$K_i = \frac{VK_i}{SUM_{i\ 1}^{n} VK_i},$$

монда:

$VK_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү буенча i-критериеның авырлык коэффициенты.

7.7.10. Хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме 28 – 32 нче таблицаларда китерелә.

28 нче таблица

Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Т/с | Вазыйфа исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. | «Социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы икенче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча техник | 45 |
| 1.2. | Социаль хезмәткәр | 45 |
| 2. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Инвалидларга һөнәри юнәлеш бирү буенча белгеч | 50 |
| 2.2. | Хезмәт физиологиясе буенча белгеч | 50 |
| 2.3. | Эргономика буенча белгеч | 50 |
| 2.4. | Социаль эш буенча белгеч | 50 |
| 2.5. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор-методист | 50 |
| 2.6. | Биолог | 55 |
| 2.7. | Зоолог | 55 |
| 2.8. | Энтомолог | 55 |
| 2.9. | Медицина психологы | 55 |
| 2.10. | Инвалидларны тернәкләндерү буенча белгеч | 55 |
| 2.11. | Ионлаштыручы һәм ионлаштырмаучы нурланыш чыганакларын тикшерүдә тоту буенча эксперт-физик | 55 |
| 2.12. | Сәламәтлек саклау учреждениеләренең химик-эксперты | 55 |
| 2.13. | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча инженер | 55 |
| 2.14. | Инвалидларны һөнәри тернәкләндерү буенча консультант | 60 |
| 3. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкче вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 3.1. | Бүлек (социаль хезмәт) мөдире | 65 |

29 нчы таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Т/с | Вазыйфа исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. | Беренче дәрәҗәдәге уку-укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Тәрбияче ярдәмчесе | 5 |
| 2. | Икенче дәрәҗәдәге уку-укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Кече тәрбияче | 35 |
| 3. | Педагог хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| 3.1. | Хезмәт буенча инструктор | 45 |
| 3.2. | Физик культура буенча инструктор | 45 |
| 3.3. | Музыка җитәкчесе | 45 |
| 3.4. | Инструктор-методист | 50 |
| 3.5. | Концертмейстер | 50 |
| 3.6. | Социаль педагог | 50 |
| 3.7. | Тәрбияче | 55 |
| 3.8. | Методист | 55 |
| 3.9. | Педагог-психолог | 55 |
| 3.10. | Өлкән инструктор-методист | 55 |
| 3.11. | Өлкән тәрбияче | 60 |
| 3.12. | Өлкән методист | 60 |
| 3.13. | Укытучы | 60 |
| 3.14. | Укытучы-дефектолог | 60 |
| 3.15. | Укытучы-логопед (логопед) | 60 |

30 нчы таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Т/с | Вазыйфа исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
| --- | --- | --- |
| 1. | Структур бүлекчәләрнең фәнни хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Кече фәнни хезмәткәр | 50 |
| 1.2. | Фәнни хезмәткәр | 50 |
| 1.3. | Өлкән фәнни хезмәткәр | 60 |
| 1.4. | Әйдәп баручы фәнни хезмәткәр | 70 |
| 1.5. | Баш фәнни хезмәткәр | 80 |

31 нче таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Т/с | Вазыйфа исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
| --- | --- | --- |
| 1. | «Беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Санитар хатын-кыз | 5 |
| 1.2. | Санитар хатын-кыз (юучы) | 5 |
| 1.3. | Авыруны карау буенча кече шәфкать туташы | 5 |
| 1.4. | Хуҗа-туташ | 5 |
| 2. | «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 35 |
| 2.2. | Хезмәт терапиясе буенча инструктор | 35 |
| 2.3. | Стерильләштерү бүлмәсе шәфкать туташы | 35 |
| 2.4. | Медицина дезинфекторы | 35 |
| 2.5. | Балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы буенча табиб (туклану гигиенасы буенча табиб, хезмәт гигиенасы буенча табиб, гигиена тәрбиясе бирү буенча табиб, коммуналь гигиена буенча табиб, гомуми гигиена буенча табиб, табиб-паразитолог, радиация гигиенасы буенча табиб, табиб-эпидемиолог) | 37 |

| | | |
|---|---|---|
| | ярдәмчесе | |
| 2.6. | Медицина теркәүчесе (регистраторы) | 35 |
| 2.7. | Диета буенча шәфкать туташы | 37 |
| 2.8. | Шәфкать туташы | 40 |
| 2.9. | Палата (пост) шәфкать туташы | 40 |
| 2.10. | Физиотерапия шәфкать туташы | 40 |
| 2.11. | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| 2.12. | Фельдшер | 45 |
| 2.13. | Процедура бүлмәсе шәфкать туташы | 45 |
| 2.14. | Бәйләү бүлмәсе шәфкать туташы | 45 |
| 2.15. | Өлкән шәфкать туташы (акушер, фельдшер, операция шәфкать туташы, теш техникы) | 50 |
| 3. | «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | |
| 3.1. | Табиб-белгечләр (3 нче һәм 4 нче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 60 |
| 3.2. | Дәвалау-профилактика учреждениеләренең, ашыгыч медицина ярдәме станцияләре (бүлекләре) стационар бүлекчәләре табиб-белгечләре | 63 |
| 3.3. | Участок табиб-терапевтлар | 63 |
| 3.4. | Гомуми практика табиблары (гаилә табиблары) (дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 63 |
| 3.5. | Өлкән табиб | 65 |
| 4. | «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) житәкчеләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| 4.1. | Структур бүлекчә (бүлек, бүлек, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдире (стационарларның хирургия юнәлеше бүлекләре мөдирләреннән кала) | 70 |

32 нче таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Т/с | Вазыйфа исеме | Авырлык коэффициентларының җыелма чик күләме |
|---|---|---|
| 1. | «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.1. | Мәдәни чаралар оештыручы | 35 |
| 1.2. | Аккомпаниатор | 35 |
| 2. | «Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Китапханәче | 40 |
| 2.2. | Мөхәррир | 40 |

## 8. Компенсация характерындагы түләүләр

8.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларында һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрендә компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр;

хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

нормадан тайпыла торган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификацияле эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берьюлы башкарганда, эш сәгатеннән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормадан тайпыла торган башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр.

8.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларның күләмнәре һәм аларны гамәлгә ашыру шартлары күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар, хезмәт турындагы законнар нигезендә хезмәт шартнамәсе һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокук актлары, бу Тәртип белән билгеләнә.

8.3. Белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә икенче һәм өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары»,«Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә җитәкчеләр вазыйфалары», «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы», «Табиблар һәм провизорлар», «Учреждениеләр структур бүлекчәләренең югары медицина һәм фармацевтика белемле (табиб-белгеч, провизор) җитәкчеләре» һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә, мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хеметкәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sm} = O_{d1} \times D_{sm},$$

монда:

$B_{sm}$ – белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләү;

$O_{d1}$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең дүрт

разрядлы тариф челтәренең беренче разряды вазыйфаи оклады күләме;

$D_{sm}$ – белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен өстәмә түләү күләме.

Белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен өстәмә түләү күләме 25 процент тәшкил итә.

Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр шулай ук шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә оештырылган түбәндәге шәһәр җирлекләрендә урнашкан Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә бирелә:

Апас;

Балтач;

Байлар Сабасы;

Балык Бистәсе.

Авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр авыл җирендә социаль хезмәтләр күрсәтүче, «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә икенче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һәм «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә.

8.4. Хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә һәм нормадан тайпыла торган шартларда эшләгән өчен (берничә һөнәрне (вазыйфаны) берьюлы башкарганда, эш сәгатеннән тыш эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормадан тайпыла торган башка шартларда эшләр башкарганда) компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{kh} = O_d \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

монда:

$B_{kh}$ – компенсация характерындагы түләү;

$D_{kh}$ – компенсация характерындагы түләү өчен өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнарда компенсация характерындагы түләү күздә тотылган фактта эшләгән вакыт;

$H_N$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең база оклады (эш хакы ставкасы) өчен сәгатьләрнең Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган нормасы.

Нормадан тайпыла торган шартларда эшләгән өчен түләүләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

төнлә эшләгән һәр сәгать өчен нормаль шартларда эшләгән белән чагыштырганда арттырылган, әмма хезмәт турындагы законнарда һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокук актлары белән

билгеләнгәннән ким булмаган күләмдә түләнә;

хезмәткәрне аңа график белән билгеләнгән ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткәндә эш өчен кимендә икеләтә күләмдә түләнә:

әгәр дә эш ял көнендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көнендә эш вакытының айлык нормасы чикләрендә башкарылса, вазыйфаи оклад алучы хезмәткәрләргә – окладтан тыш кимендә берәр көндезге яки сәгатьләп түләнә торган база ставкасы күләмендә һәм, әгәр эш айлык нормадан тыш башкарылса, база окладыннан тыш кимендә икеләтелгән көндезге яки сәгатьләп түләнә торган ставка күләмендә;

ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәрнең теләге буенча аңа башка ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта эш көне булмаган бәйрәм көненә бер эш көне күләмендә түләнә, ә ял көне өчен түләнми;

хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә хезмәт шартлары нормаль булган эшләрнең төрле төрләре өчен билгеләнгән окладлар (вазыйфаи окладлар), эш хакы ставкалары белән чагыштырганда база окладының кимендә 0,04 күләмендә арттырылган күләмдә билгеләнә;

эш сәгатеннән соң эшләгән өчен түләү эшнең беренче ике сәгате өчен кимендә бер ярым тапкырга арттырылган күләмдә, аннан соңгы сәгатьләр өчен кимендә икеләтелгән күләмдә гамәлгә ашырыла;

һөнәрләрне (вазыйфаларны) берьюлы башкарганда, хезмәт күрсәтү зоналары киңәйтелгәндә, эшнең күләме арттырылганда яки хезмәт шартнамәсе белән билгеләнгән эштән азат итмичә вакытлыча урында булмаган хезмәткәрнең вазыйфаларын үтәгәндә хезмәткәргә өстәлмә түләнә. Өстәлмә күләме хезмәт шартнамәсе яклары килешүе буенча өстәмә эшнең эчтәлеген һәм (яки) күләмен исәпкә алып билгеләнә.

8.5. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесе экономия фонды акчасы исәбеннән сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр, мәгариф хезмәткәрләре, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә аларга социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән, әмма аларның хезмәт функцияләрен гамәлгә ашыруына бәйле булмаган социаль түләүләр билгели ала.

Социаль түләүләр, аларның күләмнәре һәм аларны гамәлгә ашыру шартлары күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар, хезмәт турындагы законнар нигезендә хезмәт шартнамәсе һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокук актлары, бу Тәртип белән билгеләнә.

## 9. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесенең, җитәкчесе урынбасарының һәм баш бухгалтерының эш хакын билгеләү тәртибе

9.1. Җитәкченең, җитәкче урынбасарының һәм баш бухгалтерның эш хакы

вазыйфаи окладтан, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

9.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесенең вазыйфаи оклады гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен (алга таба – гамәлгә куючы) башкаручы орган җитәкчесе тарафыннан җитәкчегә вазыйфаи оклад билгеләнгән елның 1 гыйнвары хәленә карата төп персонал тарификациясе нигезендә Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең төп персоналына керә торган хезмәткәрләре уртача эш хакына карата икеләтелгән мөнәсәбәттә елга бер тапкыр билгеләнә.

Җитәкченең вазыйфаи окладын хисаплап чыгарганда төп персоналга керә торган хезмәткәрләрнең окладлары (вазыйфаи окладлары), стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләренең аерым төрләре исәпкә алына.

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең төп персоналына аларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе төзелгән төп функцияләрне үтәүне турыдан-туры тәэмин итүче хезмәткәрләр керә. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе хезмәткәрләре вазыйфалары һәм һөнәрләре исемлеге Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

9.3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесе вазыйфаи оклады түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$O_{d_r} = SUM_{j=1}^{n} \frac{(O_d + B_{sm} + B_{kk} + B_{pz} + B_{ysp} + B_s + B_{sd} + B_{sr} + B_{ysz} + B_{sop})}{h} \times 2 \times K_{got},$$

монда:

$O_{d_r}$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесенең вазыйфаи оклады;

$h$ – штат расписаниесе нигезендә төп персонал ставкалары саны;

$K_{got}$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчеләре хезмәте өчен түләү төркемнәре буенча 33 нче таблица нигезендә кабул ителә торган коэффициент.

33 нче таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчеләре хезмәте өчен түләү төркемнәре буенча коэффициентлар

| Т/с | Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчеләре хезмәте өчен түләү төркеме | Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчеләре хезмәте өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | 1 | 1,00 |
| 2. | 2 | 0,90 |
| 3. | 3 | 0,75 |
| 4. | 4 | 0,65 |
| 5. | Төркемнән тыш | 0,55 |

9.4. Җитәкчеләр хезмәте өчен түләү төркеме Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе эшчәнлегенең 34 нче таблицада китерелгән күләм тасвирнамәләре нигезендә билгеләнә.

34 нче таблица

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе хезмәте өчен түләү төркемен тасвирлый торган күләм күрсәткечләре

| Т/с | Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре типлары (җитәкче хезмәте өчен түләү төркеме) | Күрсәткеч (мәгънә) исеме |
|---|---|---|
| 1. | Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (стационар формалы социаль хезмәт күрсәтә торган), балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре, билгеле яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләре | смета буенча койкалар саны |
| 1.1. | I | 51 һәм аннан да күбрәк |
| 1.2. | II | 31 – 50 |
| 1.3. | III | 16 – 30 |
| 1.4. | IV | 15 кә кадәр |
| 2. | Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге, өлкән инвалидлар, шул исәптән сукыр һәм начар күрүчеләр өчен социаль-тернәкләндерү оешмасы җитәкчесе, смета буенча койкалар санына карамастан, хезмәт өчен түләү буенча I төркемгә керә | |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Социаль хезмәт күрсәтү оешмасы (ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтә торган), халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләре, халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү үзәкләре | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге халкы саны |
| 3.1. | I | 151000 нән артык |
| 3.2. | II | 101000 – 150000 |
| 3.3. | III | 50000 – 100000 |
| 3.4. | IV | 50000 гә кадәр |
| 4. | Картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортлар, психоневрология интернатлары, акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йортлары-интернатлар, физик кимчелекләре булган балалар өчен балалар йортлары-интернатлар, картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортлар (пансионатлар) | смета буенча койкалар саны |
| 4.1. | I | 151 һәм аннан да күбрәк |
| 4.2. | II | 101 – 150 |
| 4.3. | III | 50 – 100 |
| 4.4. | IV | до 50 |

Структурасында социаль-тернәкләндерү бүлеге булган халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк җитәкчесе оклады 10 процентка арттырылырга тиеш.

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» һәм «Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге» дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләренә хезмәт өчен түләү буенча 1 төркем билгеләнә.

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесе хезмәте өчен түләү төркеме гамәлгә куючы тарафыннан эшләрнең тиешле төрләре һәм күләмнәре булуны раслый торган документлар нигезендә елга бер тапкырдан арттырмыйча билгеләнә.

Яңа төзелгән Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесе хезмәте өчен түләү төркеме аның тибы үзгәрүгә бәйле рәвештә план (проект) күрсәткечләреннән чыгып билгеләнә.

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесенең вазыйфаи оклады күләме ел саен гамәлгә куючы приказы белән билгеләнә, шулай ук җитәкченең хезмәт шартнамәсенә өстәмә шартнамә белән рәсмиләштерелә.

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләрен төзегәндә һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының

һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең төп персоналы хезмәткәрләренең; уртача эш хакын хисаплап чыгарып булмаган башка очракларда халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчесенең вазыйфаи окладын, халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчесенең вазыйфаи оклады күләме гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Җитәкчеләр урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның вазыйфаи окладлары Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчеләренең вазыйфаи окладлары күләмнәреннән 10 – 30 процентка кимрәк күләмдә билгеләнә.

9.5. Компенсация характерындагы түләүләр Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесе, җитәкчесе урынбасарлары һәм баш бухгалтеры өчен хезмәт турындагы законнар белән раслана торган компенсация характерындагы түләүләр төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.

9.6. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесе, җитәкчесе урынбасарларына, баш бухгалтерына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне, җитәкче урынбасарлары, баш бухгалтер эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлекләре нәтиҗәләрен исәпкә алып, вазыйфаи окладның 100 процентына кадәр күләмдә билгели.

Түләүләр бу Нигезләмәнең 10.2 нче пункты нигезендә һәм Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең хезмәт өчен түләү фонды буенча акчаны экономияләүдән формалаштырылган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесен, җитәкчесе урынбасарларын, баш бухгалтерын стимуллаштыру фондыннан 50 процент күләмендә гамәлгә ашырыла.

Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел өчен эш йомгаклары буенча, әһәмиятле һәм аеруча әһәмиятле эшләр башкарган өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

9.7. Гамәлгә куючы Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе эшчәнлегенең эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән нәтиҗәләрен исәпкә алып, вазыйфаи окладның 100 процентына кадәр күләмдә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгели.

Түләүләр бу Нигезләмәнең 10.2 нче пункты нигезендә һәм Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең хезмәт өчен түләү фонды буенча акча экономияләүдән формалаштырылган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе

җитәкчесен, аның урынбасарларын, дәүләт учреждениесенең баш бухгалтерын стимуллаштыру фондыннан 50 процент күләмендә гамәлгә ашырыла.

Җитәкчегә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, ел өчен эш йомгаклары буенча, әһәмиятле һәм аеруча әһәмиятле эшләр башкарган өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

9.8. Ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләрен стимуллаштыру турындагы карарлар гамәлгә куючының норматив хокук акты белән рәсмиләштерелә.

9.9. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү турындагы нигезләмәләр гамәлгә куючы һәм җитәкче, җитәкче һәм җитәкче урынбасары һәм баш бухгалтер арасында төзелә торган хезмәт шартнамәсендә яки хезмәт шартнамәсенә өстәмә шартнамәдә чагыла. Хезмәт шартнамәсенә өстәмә шартнамә бер елга кадәр вакытка төзелә. Календарь ел үткәннән соң хезмәт шартнамәсенә өстәмә шартнамә җитәкче, җитәкченең урынбасарлары һәм баш бухгалтер хезмәтен стимуллаштыруның гомуми фонды күләмнәрен, шулай ук Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары исемлекләрен һәм мәгънәләрен үзгәртү өлешендә яңадан каралырга мөмкин.

## 10. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе

10.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасында һәм дәүләт социаль яклау учреждениесендә хезмәт өчен түләү фонды финанслауның норматив күләме, хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына акча күләме чикләрендә төзелә һәм Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

10.2. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасында һәм дәүләт социаль яклау учреждениесендә күләме түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла торган җитәкчене, җитәкче урынбасарларын һәм баш бухгалтерны стимуллаштыру фонды булдырыла:

$$FOT_k = FOT_{uch} \times D_k,$$

монда:

$FOT_k$ – җитәкчене, җитәкче урынбасарларын һәм баш бухгалтерны стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды;

$FOT_{uch}$ – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең хезмәт өчен түләү фонды;

$D_k$ – җитәкченең, җитәкче урынбасарларының һәм баш бухгалтерның стимуллаштыру характерындгы түләүләренә хезмәт өчен түләү фонды өлеше.

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесен, җитәкчесе урынбасарларын һәм баш бухгалтерын стимуллаштыруга хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасының һәм дәүләт социаль яклау учреждениесенең хезмәт өчен түләү фондының 1 процентына тигез дип кабул ителә.

10.3. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасында һәм дәүләт социаль яклау учреждениесендә башкарыла торган эшнең сыйфаты өчен күләме түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла торган стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды булдырыла:

$$FOT_k = FOT_{do} \times D_k,$$

монда:

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды;

$FOT_{do}$ – хезмәткәрләрнең төп эш урыны буенча вазыйфаи окладлар (окладлар, эш хакы ставкалары) буенча Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү фонды;

$D_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәт өчен түләү фонды өлеше.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, эш хакы ставкалары) буенча Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү фондының 5 проценты күләмендә кабул ителә.

10.4. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмасында һәм дәүләт социаль яклау учреждениесендә күләме түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла торган премиаль һәм бүләкләү түләүләре фонды булдырыла:

$$FOT_{pr} = FOT_{or} \times D_{pr},$$

монда:

$FOT_{pr}$ – премиаль һәм бүләкләү түләүләре фонды;

$FOT_{or}$ – хезмәткәрләрнең төп эш урыны буенча окладлар (эш хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләүгә һәм бу Нигезләмәдә билгеләнгән стимуллаштыру характерындагы башка түләүләрне бирүгә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фонды;

$D_{pr}$ – премиаль һәм бүләкләү түләүләренә хезмәт өчен түләү фонды өлеше.

Премиаль һәм бүләкләү түләүләренә хезмәт өчен түләүнең тәкъдим ителә торган күләме хезмәткәрләрнең төп эш урыны буенча окладлар (эш хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләүгә һәм бу Нигезләмә белән билгеләнгән стимуллаштыру характерындагы башка түләүләрне бирүгә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фондының 2 процентын тәшкил итә.

---

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның билгеләнгән категорияләре белән эшләгән өчен Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре

| Т/с | Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе төре, вазыйфалар | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют | |
| 1.1. | «Социаль хезмәткәр», «бүлек (социаль хезмәт) мөдире», «социаль эш буенча белгеч», медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары | 50 |
| 1.2. | Барлык вазыйфалар (1.1 нче пунктчадан тыш) | 25 |
| 2. | Балигъ булмаган балалар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге | |
| 2.1. | Барлык вазыйфалар | 25 |
| 3. | Психоневрология интернаты | |
| 3.1. | «Социаль хезмәткәр», «бүлек (социаль хезмәт) мөдире», «социаль эш буенча белгеч», медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфалары | 50 |
| 3.2. | Барлык вазыйфалар (3.1 нче пунктчадан тыш) | 25 |
| 4. | Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар йорты-интернат | |
| 4.1. | «Социаль хезмәткәр», «бүлек (социаль хезмәт) мөдире», «социаль эш буенча белгеч», медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфалары | 50 |
| 4.2. | Барлык вазыйфалар (4.1 нче пунктчадан тыш) | 15 |
| 5. | Картлар һәм инвалидлар өчен интернат йорт (пансионат) | |
| 5.1. | «Социаль хезмәткәр», «бүлек (социаль хезмәт) мөдире», «социаль эш буенча белгеч», медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфалары | 50 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 5.2. | Барлык вазыйфалар (5.1 нче пунктчадан тыш) | 10 |
| 6. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк | |
| 6.1. | «Социаль хезмәткәр», «бүлек (социаль хезмәт) мөдире», «социаль эш буенча белгеч», медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфалары | 15 |
| 6.2. | Барлык вазыйфалар (6.1 нче пунктчадан тыш) | 5 |
| 7. | Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге | |
| 7.1. | Барлык вазыйфалар | 5 |
| 8. | Халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтү үзәге | |
| 8.1. | Барлык вазыйфалар | 5 |
| 9. | Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәге | |
| 9.1. | Барлык вазыйфалар | 50 |
| 10. | Картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йорт | |
| 10.1. | Барлык вазыйфалар | 50 |
| 11. | Инвалидларны тернәкләндерү үзәге | |
| 11.1. | Барлык вазыйфалар | 10 |
| 12. | Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге | |
| 12.1. | «Социаль хезмәткәр», «бүлек (социаль хезмәт) мөдире», «социаль эш буенча белгеч», медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфалары | 25 |
| 12.2. | Барлык вазыйфалар (12.1 нче пунктчадан тыш) | 15 |
| 13. | Халыкка социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгеләү һәм түләү эшен гамәлгә ашыручы социаль яклау учреждениеләре | |
| 13.1. | Барлык вазыйфалар | 25 |
| 14. | Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге | |
| 14.1. | Барлык вазыйфалар | 15 |

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен аларның булуы нигез булып торучы Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре исемлеге

| Т/с | Мактаулы исем, дәүләт бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре |
| 1.1. | Россия Федерациясенең атказанган табибы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган укытучысы |
| 2. | Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре |
| 2.1. | Татарстан Республикасы Мактау грамотасы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының атказанган табибы |
| 2.4. | Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 2.6. | Татарстан Республикасының атказанган укытучысы |
| 3. | Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре |
| 3.1. | СССРның Халык табибы |
| 3.2. | СССРның Халык укытучысы |
| 4. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1. | Халык табибы |
| 4.2. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 4.3. | Атказанган табиб |
| 4.4. | Атказанган социаль тәэмин итү хезмәткәре |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 4.5. | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.6. | Атказанган укытучы |
| 4.7. | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 5. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре |
| 5.1. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 5.2. | Атказанган табиб |
| 5.3. | Атказанган мәктәп укытучысы |

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының
һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә
стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен аларның булуы нигез
булып торучы Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет
Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы
составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре,
дәүләт бүләкләре исемлеге

| Т/с | Мактаулы исем, дәүләт бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре һәм ведомство (тармак) бүләкләре |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык укытучысы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган производствога өйрәтү мастеры |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 1.5. | Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.6. | Россия Федерациясенең атказанган укытучысы |
| 1.7. | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 1.8. | Россия Федерациясенең атказанган гомуми белем бирү хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең атказанган башлангыч һөнәр белеме бирү хезмәткәре |
| 1.10. | Россия Федерациясенең атказанган урта һөнәр белеме бирү хезмәткәре |
| 1.11. | Россия Федерациясенең атказанган югары һөнәр белеме бирү хезмәткәре |
| 1.12. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы |
| 1.13. | Россия Федерациясенең атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 2. | Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе |
| 2.3. | Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 2.4. | Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган укытучысы |
| 2.6. | Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы |
| 2.7. | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.8. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2.9. | Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 3. | Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре |
| 3.1. | ССРның Халык укытучысы |
| 3.2. | ССРның атказанган тренеры |
| 4. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1. | Атказанган физик культура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2. | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 4.3. | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.5. | Атказанган тренер |
| 4.6. | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.7. | Атказанган укытучы |
| 4.8. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.9. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 4.10. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.11. | Атказанган укытучы |
| 4.12. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.13. | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 4.14. | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 4.15. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.16. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре |
| 5.1. | Атказанган физик культура һәм спорт эшлеклесе |
| 5.2. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 5.3. | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 5.4. | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.5. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 5.6. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 5.7. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 5.8. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.9. | Атказанган  фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.10. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.11. | Атказанган фән эшлеклесе |

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен аларның булуы нигез булып торучы Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре исемлеге

| Т/с | Мактаулы исем, дәүләт бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре |
| 1.1. | Россия Федерациясенең атказанган табибы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2. | Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре |
| 2.1. | Татарстан Республикасы Мактау грамотасы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының атказанган табибы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе |
| 2.4. | Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 3. | Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре |
| 3.1. | СССРның Халык табибы |
| 4. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1. | Халык табибы |
| 4.2. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 4.3. | Атказанган табиб |
| 4.4. | Атказанган провизор |
| 4.5. | Атказанган фармацевт |
| 4.6. | Атказанган укытучы |
| 4.7. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 4.8. | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 4.9. | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 4.10. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.11. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре |
| 5.1. | Атказанган медицина хезмәткәре |
| 5.2. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 5.3. | Атказанган табиб |
| 5.4. | Атказанган провизор |
| 5.5. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.6. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.7. | Атказанган фән эшлеклесе |

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 5 нче кушымта

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен аларның булуы нигез булып торучы Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре исемлеге

| Т/с | Мактаулы исем, дәүләт бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре |
| 1.1. | Россия Федерациясенең атказанган табибы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 2. | Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре |
| 2.1. | Татарстан Республикасы Мактау грамотасы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының атказанган табибы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 3. | Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре |
| 3.1. | СССРның Халык табибы |
| 4. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1. | Халык табибы |
| 4.2. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 4.3. | Атказанган табиб |
| 4.4. | Атказанган провизор |
| 4.5. | Атказанган фармацевт |
| 5. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре |
| 5.1. | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 5.2. | Атказанган табиб |
| 5.3. | Атказанган провизор |

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 6 нчы кушымта

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү өчен аларның булуы нигез булып торучы Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре исемлеге

| Т/с | Мактаулы исем, дәүләт бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 2. | Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Мактау грамотасы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.4. | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 3. | Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре |
| 3.1. | СССРның Халык рәссамы |
| 4. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1. | Атказанган пропагандист |
| 4.2. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.3. | Халык рәссамы |
| 4.4. | Атказанган рәссам |
| 4.5. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.6. | Атказанган мәдәни-агарту эшләре хезмәткәре |
| 4.7. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.8. | Атказанган китапханәче |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 4.9. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.10. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 5. | Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре |
| 5.1. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.2. | Халык рәссамы |
| 5.3. | Атказанган рәссам |
| 5.4. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.5. | Атказанган китапханәче |
| 5.6. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 1 август, 653 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 2 апрель, 209 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 ел, 18 август, 592 нче карары нигезендә эшләнде, хезмәткәрләрнең окладларын, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрен формалаштыру тәртибен, аларның күләмнәрен һәм шартларын, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Бу Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

хезмәт өчен түләү системасы – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, база окладлары (база вазыйфаи окладлары, эш хакының база ставкалары), окладлар (вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары) күләмнәрен кертеп, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады (вазыйфаи оклад), эш хакы ставкасы – Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшче һөнәре буенча яки тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренең минималь оклады (вазыйфаи окладлы, эш хакы ставкасы), компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча;

оклад (вазыйфаи оклад, эш хакы ставкасы) – календарь аенда билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәргә хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән күләме, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча;

хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләре буенча окладлар (вазыйфаи окладлар, эш хакы ставкалары) диапазоны – хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләре буенча чикләрендә хезмәткәрләрнең окладлары (вазыйфаи окладлары, эш хакы ставкалары) билгеләнә торган минималь һәм максималь күләмнәре;

эш хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) – башкарыла торган эшнең квалификациясенә, катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына бәйле булган хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль шартлардан тайпыла торган эш өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр – стимуллаштыру характерындагы өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү түләүләре;

социаль характердагы түләүләр – социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән, хезмәт өчен түләү фонды акчасын экономияләү хисабына гамәлгә ашырыла торган, ләкин аларның хезмәт функцияләрен үтәүләренә бәйле булмаган түләүләр.

1.3. Хезмәткәрнең эш хакы (хезмәт өчен түләве) түбәндәгеләрдән билгеләнә:

окладлардан (вазыйфаи окладлардан), эш хакы ставкаларыннан;

компенсация характерындагы түләүләрдән;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән.

## 2. Хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибе

2.1. Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының (алга таба – эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары) һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең база оклады күләме эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча минималь база окладының (вазыйфаи окладның, эш хакы ставкасының) эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча тиешле арттыру коэффициентына тапкырчыгышы буларак билгеләнә.

2.2. Минималь база окладын (вазыйфаи оклад, эш хакы ставкасы) күләмен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

2.3. Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча хезмәткәрнең база окладын (эш хакының база ставкасы) түбәндәге формула

буенча исәпләп чыгарыла:

$$O_d = T \times K_{d_i},$$

монда:

$O_d$ – эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча хезмәткәрләр оклады (вазыйфаи оклады, эш хакы ставкасы);

Т – минималь база оклады (вазыйфаи оклад, эш хакы ставкасы) күләме;

$K_{d_i}$ – эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча тиешле арттыру коэффициенты.

2.4. Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча арттыру коэффициентлары күләмнәре диапазоннары 1, 2 нче таблицаларда китерелә.

1 нче таблица

Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре буенча арттыру коэффициентлары күләмнәре диапазоны

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Арртыру коэффициентлары күләмнәре диапазоны |
|---|---|---|---|
| 1. | Беренче дәрәҗәдәге эшчеләр гомумтармак һөнәрләре | 1 | 1,00 – 1,03 |
| | | 2 | 1,03 – 1,05 |
| 2. | Икенче дәрәждәге эшчеләр гомумтармак һөнәрләре | 1 | 1,03 – 1,07 |
| | | 2 | 1,07 – 1,13 |
| | | 3 | 1,13 – 1,17 |
| | | 4 | 1,17 – 1,50 |

2 нче таблица

Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренең арттыру коэффициентлары күләмнәре диапазоны

| Т/с | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Арттыру коэффициентлары күләмнәре диапазоны |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары | 1 | 1,00 – 1,03 |
| | | 2 | 1,03 – 1,07 |
| 2. | Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары | 1 | 1,03 – 1,07 |
| | | 2 | 1,07 – 1,10 |
| | | 3 | 1,10 – 1,13 |
| | | 4 | 1,13 – 1,20 |
| | | 5 | 1,20 – 1,33 |
| 3. | Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары | 1 | 1,10 – 1,13 |
| | | 2 | 1,13 – 1,20 |
| | | 3 | 1,20 – 1,33 |
| | | 4 | 1,33 – 1,47 |
| | | 5 | 1,47 – 1,57 |
| 4. | Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары | 1 | 1,57 – 1,73 |
| | | 2 | 1,73 – 2,00 |
| | | 3 | 2,00 – 2,67 |

2.5. Эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча арттыру коэффициентлары күләмнәре хезмәткәрнең вазыйфасы яки һөнәре кертелгән һөнәри квалификация төркеменең квалификация дәрәҗәсе өчен билгеләнгән арттыру коэффициентлары диапазонының түбән чигеннән ким була алмый.

2.6. Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм һөнәре эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренең тиешле квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокук актлары нигезендә кабул ителә.

2.7. Ике эштә берьюлы, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә йә эшләрнең башкарылган күләменә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы ике эш башкару тәртибендә билгеләнә торган вазыйфа буенча эш хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла.

## 3. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

3.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфатлы нәтиҗәсенә ирешүгә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

3.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

интенсивлылык һәм эшнең югары нәтиҗәләре өчен түләүләрне;

вазыйфа буенча эш стажы өчен түләүләрне;

премиаль һәм башка бүләкләү түләүләрен.

3.3. Интенсивлылык һәм эшнең югары нәтиҗәләре өчен түләүләр

түбәндәгеләргә бүленә:

эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;

эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен түләүләр;

мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр.

3.4. Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның билгеләнгән категориясе белән эшләгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә. Бүлекчәдә тәгаен эш шартларын һәм вазыйфаларын (һөнәрләрне) исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазыйфалары (һөнәрләре) исемлеге, сайланулы һөнәр берлеге органы (хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмасы һәм дәүләт социаль яклау учреждениесе җитәкчесе тарафыннан раслана.

«Җитештерү мөдире (шеф-пешекче)», «ашханә мөдире» вазыйфалары буенча җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һәм «аш пешерүче» вазыйфасы буенча эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр 20 процент күләмендә бирелә.

3.5. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

3.6. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

3.7. Хезмәткәрләргә тиешле түләүләр бирү өчен аларның булуы нигез булып торучы мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре исемлеге бу Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.

3.8. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән гамәлгә ашырыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме, ике аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү хезмәткәрнең теләге буенча мактаулы исемнең берсе, дәүләт бүләгенең берсе буенча билгеләнә.

3.9. Эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен түләүләр, башкарыла торган эшнең катлаулылыгын һәм мөһимлеген, куелган бурычларны үтәгәндә мөстәкыйльлек һәм җаваплылык дәрәҗәсен исәпкә алып, житәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен түләү;

$D_{sr}$ – эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме.

3.10. Эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме 5 процент тәшкил итә.

3.11. Вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләүләр, вазыйфа (белгечлек) буенча эшнең дәвамлылыгына карап, һөнәри-квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре яктылыгында стаж төркемнәре буенча житәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$ – вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы өчен түләү;

$D_s$ – вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

3.12. Вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре түбәндәгеләрне тәшкил итә:

вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы 2 елдан 5 елга кадәр булганда – 2,5 процент;

вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы 5 елдан 10 елга кадәр булганда – 4 процент;

